ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.10.2025 с. Набережные Моркваши №12

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннары йөрү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә, гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтенең сакланышын тәэмин итә торган йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында,Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. гражданнар файдалануында яисә милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. кешеләр күпләп җыелмый торган авыл җирлегендә (тыкрыклар, бушлыклар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннар) урыннар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге БК җитәкчесе К.Г.Саттарова